**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Аксумла авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР**

**08 ноябрь 2024 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», 2024 елның 8 ноябрендә узган: «2025 елда Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Аксумла авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, бачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан кала, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пунктлар территорияләрен төзекләндерү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 301 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 179 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 172 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 7 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Аксумла авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2025 елда Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Аксумла авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, бачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан кала, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пунктлар территорияләрен төзекләндерү.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен "Интернет" мәгълүмат-телекоммуция челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Нурлат муниципаль

районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Аксумла авылындагы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенә Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Г.Н. Лизратова

Әхмәт авыл җирлеге башлыгы: Г.Н. Лизратова